www.as-salam.ru
www.islamdag.ru
assalamweb@gmail.com
assalam_tatar
12+

# ӘС-СӘЛАМ

ДИН-МӘГЪРИФӘТ ГАЗЕТАСЫ

Бәясе ирекле

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ МАКТАУЛАР БУЛСЫН!

Рәҗәб 1438 ел. 1994 нче елдан бирле бастырыла. № 4 (05) / 15 апрель 2017 ел.

## Казанда Татарстан мөселманнарының VII Корылтае үтте

**17 апрельдә Казанда Татарстан мөселманнарының чираттагы VII Корылтае булып узды. Чара Коръән аятьләре укып һәм дога кылып башланды. Беренчеләрдән булып делегатларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләде.**



Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев 2013-2017 елларда башкарган эшчәнлеккә нәтиҗәләр ясады. Шулай ук делегатлар игътибарына Нәзарәтнең үзәк ревизия комиссиясе хисабы да тәкъдим ителде.

Камил хәзрәт үзенең чыгышында, 4 ел дәвамында башкарылган эшләрдән тыш, киләчәктә мөселман өммәте каршында торган бурычларны да барлады. Бүген Нәзарәт составына 1415 теркәлгән мәхәллә һәм 1430 мәчет керә. Аларда 1400 имам хезмәт итә. Бу – Россия Федерациясендә эшләп килгән бөтен мәхәллә һәм мәчетләрнең чирегеннән күбрәк. Шул ук вакытта соңгы 4 ел эчендә генә республикада 50дән артык яңа мәчет ачылган.

Шушы дәвердә Диния нәзарәте эшчәнлекне бердәй кануни үрнәккә яраклаштыруга, мөселман мәгариф системасы үсешенә, социаль сәясәтне тормышка ашыруга, экстремистлык чагылышларына каршы торуга аеруча зур игътибар бирелгән.

Диния нәзарәте, гадәттәгечә, хаҗиларга күрсәтелгән хезмәтнең сыйфатын яхшыртуга зур әһәмият бирә. Ислам Ватанына туры рейслар оештыру, хаҗиларны укыту, аларның туклану һәм торак мәсьәләсен кайгырту – боларның барысы да Татарстандагы «ДУМ РТ Хаж» рәсми хаж-операторының игътибар үзәгендә. Шушы хисап чорында, «ДУМ РТ Хаж» хезмәтләреннән кулланып, 7000нән артык мөселман хаж кылган.

Татарстанда хәләл өлкәсен үстерүдә «Хәләл» стандартлары комитеты мөһим роль уйный. Бүген Комитет реестрында хәләл продукция җитештерә торган 96 сертификацияләнгән оешма бар, шуларның 49ы Татарстаннан булса, 47се – Россиянең башка төбәкләреннән.

Хисап докладларыннан соң мөфти, аның беренче урынбасары, баш казый һәм үзәк ревизия комиссия әгъзаларын сайлау узды. Делегатлар бертавыштан мөфти итеп Камил хәзрәт Сәмигуллинны, беренче урынбасар итеп – Рөстәм хәзрәт Вәлиуллинны, баш казый итеп – Җәлил хәзрәт Фазлыевны сайлады.

Шулай ук Корылтайда катнашучылар Нәзарәтнең уставына үзгәрешләр дә кабул итте.

Татарстан мөселманнарының VII Корылтае дәүләт бүләкләре тапшыру һәм Коръән укып тәмамланды.

3НЧЫ БИТ

НӘСЫЙХӘТ

## Халык мәдрәсәсендә

Кукмараның башлангыч мәдрәсәсе капка төбенә килеп туктауга, мондагы җиңел машиналарның күплегенә гаҗәпләнеп: «Бүген биредә бербер җыелыш, очрашу, бәйрәмме әллә?» – дип соравымны сизми дә калдым.

– Юк, һәр якшәмбе шушылай. Авыллардан киләләр машина-машина. Көнозын дәресләр бара. Ерак авыллардан гына түгел, күрше Мамадыштан, Сабадан, Киров өлкәсеннән йөреп укучылар саны елданел ишәя, – дип аңлатты юлдашым Фәния ханым Җәләлиева, дин-ислам нигезләрен үзләштерергә тырышучы якташлары белән горурланып.

7НЧЕ БИТ

ГАИЛӘ

## Мөслимәләр өчен

Бу хатны укыгач, бөтен социаль челтәрләрдән чыгарга булдым.

Мин Әсма. Гап-гади гарәп гаиләсендә үстем. Иремне, гаиләмне бик яратам. Раббыма шөкер, миңа бик күркәм холыклы, мәрхәмәтле ир насыйп булды.

Дүрт ел элек мин Лондонга күченеп килдем. Ирем миңа шәһәрнең иң матур урыннарын күрсәтте, мин үземне бик бәхетле хис иттем.

Минем Мөхәммәд исемле 3 яшьлек улым һәм 1,5 яшьлек кызым Әдилә бар иде. Бөтен барлыгымны мин аларга багышладым, дөрес тәрбия бирергә тырыштым.

Ирем Лондонда ресторанда хезмәт куя. Ике ай элек ул миңа бик яхшы смартфон бүләк итте.

4НЧЕ БИТ

## Коръәни-Кәримгә мәдхия бәйрәме

ВӘСИЛӘ РӘХИМОВА

Өммәтебез бәйрәмнәре хакында сүз чыкса, Ураза һәм Корбан гаетләрен, һәр атнаның җомгасын олылап билгеләвебезне әйтәбез. Әмма соңгы 20 елда дин кардәшләребезнең рәхәтләнеп үзара күрешә, Коръән укуда ярыша, нәсыйхәтләр, нәшидләр, мөнәҗәтләр тыңлап, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (салләллаһу галәйһи вәссәлам) хакында фильмнар карап кинәнә торган бәйрәмнәре дә, аралашырга, гыйбрәтләнүгә, үрнәк алуга этәргеч биргән чаралары да, әлхәмдулиллаһ, шактый күп.



Барлый башласаң, исемлек шактый озын. Зур-зур залларда Рәсүлебез (салләллаһу галәйһи вәссәлам) дөньяга килгән айны олылап билгеләп үтүләребез, Мәүлидән-Нәби бәйрәменә җыелуларыбыз, берьюлы меңнәрчә мөселманны авыз ачтырган ифтар мәҗлесләрен, Корбан ашларын да үзенә бер зур бәйрәмгә әйләндерүебез, рәхәтләнеп катнашуыбыз хак.

Быел яз буе күңелем үзгә бер халәт кичерә. Бүген дин-исламыбыз тормышын яктыртучы кайсы гына электрон мәгълүмат чараларын – сайтларны ачма, балалар, хатын-кызлар, ир-атлар арасында Коръән уку бәйгеләре, оста итеп азан әйтү бәйгеләре дисеңме, мөнәҗәтчеләрне тыңлау, иң яхшы вәгазьчеләрне ачыклаумы, каллиграфия сәнгате кызыксындырамы – теләгәнеңне сайлап ал.

Бәйрәм түгелме болар?!

Дин кардәшләребезне үзара таныту, аеруча сәләтле, ихласлыларны ачыклау, килешегез, кем өчендер үзенә бер тәрбия сәгате, үрнәк итеп алу, камилләшүгә этәрүче дәрес тә бит әле!

7НЧЕ БИТ

### Татар вәгазь теле үзенчәлекләре



5НЧЕ БИТ

### Мөселман кешесенә тиешле булган 10 сыйфат



5НЧЕ БИТ

### Авыл конференциясе



4НЧЕ БИТ

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

### Татарстан мөселманнары Санкт-Петербург метросында һәлак булучылар рухына дога кылды

Казанның һәм Татарстанның барлык мәчетләрендә Санкт-Петербург метросында шартлау нәтиҗәсендә үлгән кешеләрнең рухларына дога кылдылар. Татарстан мөселманнары Аллаһы Тәгаләдән, яраланып, хастаханәләрдә ятучыларның тизрәк сәламәтләнүен, ә мәрхүмнәрнең рухлары тыныч, оҗмахта булуын сорады. Бүген дин әһелләре шулай ук Санкт-Петербургтагы теракта зыян күрүчеләргә ярдәм йөзеннән донорлык акциясендә дә кушылды.

### Коръән укучылар бәйгесе: Хаҗга Баулы, Кукмара, Чаллы һәм Әлмәт мөслимәләре бара

Баулыда хатын-кызлар арасында Коръәннең соңгы 3 өлешен белүче хатын-кызлар арасында бәйгә узды. Чараны республика мөселманнары Диния нәзарәте, ТР көньяк-көнчыгыш казыяты, Баулы мөхтәсибәте һәм Баулы районы администрациясе оештырды.

– Ир кешене Коръән укырга өйрәтсәң, бер кешегә бирелә. Хатын-кызга Коръән гыйлемен бирсәң, бер нәселгә белем биргән буласың, – дип искә төшерде Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) сүзләрен көньяк-көнчыгыш казые Марат хәзрәт Мәрданшин ачылыш тантанасында. – Аллаһ юлын сайлавыгыз өчен бик зур рәхмәт сезгә, хөрмәтле мөслимәләребез. Сезнең кебек хатын-кызлар булганда, өммәтебезнең киләчәге бар һәм ул якты. Ачылыш тантанасында катнашучыларны Баулы районы башлыгы урынбасары Ренат Хәмидуллин, имам-мөхтәсиб Әнвәр хәзрәт Хәмитов, нәзарәтнең Коръәнне өйрәнү бүлеге җитәкчесе Илнур хәзрәт Хәйруллин һәм фән һәм уку-укыту бүлеге җитәкчесе Айдар Кәрибуллин сәламләде. Ярышта республиканың 19 мөхтәсибәте һәм Башкортстан, Чиләбе вәкилләре катнашты. Хатын-кызлар Изге Коръәннең соңгы 3 җөзен белүдәге ярышны ике яшь төркеменә бүленеп үтте: 18 яшькә кадәр һәм аннан өлкәнрәк. Бәйгенең иң яшь катнашучысына бары 7 генә яшь. Сабый гына булуына карамастан, Хәдичә Хаҗиева Коръәннең 22 җөзен белә. Ул мөфти Камил хәзрәт кулыннан махсус бүләккә ия булды.

Ике яшь төркемендәге җиңүчеләргә һәм икенче урынга лаек булучыларга төп бүләк – хаҗга юллама тапшырылды.

1нче урын алучылар: Гүзәл Гәрәева (13 яшь, Чаллы); Нәзилә Шәрипова (17 яшь, Кукмара)

2нче урын: Гайшә Әүһәдиева (18 яшь, Әлмәт); Асия Мөфлихунова (16 яшь, Баулы)

Калган призерлар һәм катнашучылар кыйммәтле һәм истәлекле бүләкләр алды. Ябылу тантанасында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин ошбу чараны оештыруда ярдәм итүчеләргә рәхмәтләрен әйтте һәм зур җиңүгә ирешкән мөслимәләрне чын күңелдән котлады.

### Дин һәм фән әһелләре Татар ханнарының мәетләрен җирләү хакында сөйләште

Агымдагы елның 11 апрелендә «Кол Шәриф» мәчетендә дин һәм фән әһелләре катнашында татар ханнарының мәет калдыкларын ислам канунннары нигезендә җирләүгә багышланган җыелыш булды. Мәгълүм булганча, 1977 елда археологлар Казан Кремле территориясендә ике төрбәне ача. Галимнәр табутларда Казан ханы Мәхмүд һәм Мөхәммәдәмин сөякләре булуын ачыклый.

Эшлекле очрашуда мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, нәзарәтнең аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов, дәгъват бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, Казан казые Габдулла хәзрәт Әдһәмов, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы җитәкчесе Зилә Вәлиева, ТР фәннәр академиясе вице-президенты Рафаэль Хәкимов, тарихчы Радик Салихов, Археология институты директоры урынбасары Фаяз Хуҗин катнашты.

Дин һәм фән эшлеклеләре җирләү буенча эшләрне хан гаиләсенә тиешле хөрмәт һәм олылау күрсәтеп башкару кирәклеге турында белдерде. Айрат хәзрәт Әюпов исламда да, башка диннәрдә дә, кешене вафатыннан соң җиргә иңдерүнең кичекмәстән үтәлергә тиешле бер шарт булып торуын һәм моның ата-бабаларыбыз алдында изге бурыч булуын җиткерде.

Ханнарның җәсәден җиргә иңдерү мәсьәләсен карау киләсе утырышларның берсендә дәвам итәчәк.

## Мөфти җитәкчелегендәге мөселман җәмәгатьчелеге: «Мөселманнар кан коймый!»



Бүген Татарстанның Кан тапшыру үзәгендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, нәзарәт хезмәткәрләре, имамнар, мөселман уку йортлары шәкертләре һәм мөгаллимнәр Санкт-Петербург метросында булган фаҗигадә зыян күрүчеләргә һәм башка мохтаж кешеләргә ярдәм йөзеннән кан тапшырды. "Мөселманнар кан коймый!" дигән шигарь астында уздырылган әлеге донорлык акциясе мөселманнарның һәрвакыт ярдәм итәргә әзер булуын күрсәтү максаты белән оештырылды.

Кан бирү үзәгенең баш табибы Рамил Тураев мөселманнарның ниятен шулай ук хуплады һәм кан бирүнең җәмгыять өчен нинди зур әһәмияткә ия булуын билгеләп үтте.

Камил хәзрәт кан бирү алдыннан берничә кирәкле процедура үтте: регистрация узды, кан анализы тапшырды һәм терапевт белән аралашты. Болар барысы да канга мохтаҗ кешенең сәламәтлегенә зыян салмау өчен эшләнелә.

- Ислам дине кан бирүне тыймый, чөнки без кемнеңдер гомерен һәм саулыгын саклап калугы үз өлешебезне кертәбез, - дип билгеләде Камил хәзрәт Сәмигуллин. - Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтә: "...Әгәр берәү бер кешене үлемнән коткарса — бөтен кешеләрне үлемнән коткарган кебек булыр" (Мәидә сүрәсе, 32).

## Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәскәү укучыларына ачык дәрес бирде



Бүген Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәскәүгә эш сәфәре кысаларында 250нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары белән очрашты.

Мөфти укучыларга ислам кыйммәтләре хакында кызыклы итеп сөйләде һәм аларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде. Бүгенге очрашуда барлыгы 30 бала катнашты.

Шунысы игътибарга лаек, әлеге уку йорты рус телен тирәнрәк өйрәнүне максат итеп куя һәм биредә төрле милләт вәкилләре белем ала.

Мәктәп Мәскәү һәм Үзәк Русия нәзарәте (Мәскәү мөфтияте) белән тыгыз элемтәдә тора. Камил хәзрәтнең укучылар белән очрашуы да конфессиара элемтәләрне ныгытуны күздә тоткан проект кысаларында үткәрелде.

## Икенче Әхмәдзәки хәзрәт Сәфиуллин укулары

Агымдагы елның 4 апрелендә Диния нәзарәте бинасында дәгъват бүлеге тарафыннан оештырылган «Идел-Урал төбәгендә тәсаввуф традицияләре» дигән темага «Икенче Әхмәдзәки хәзрәт Сәфиуллин укулары» Россиякүләм фәнни-гамәли конференция булып узды. Конференция эшендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Самара өлкәсе Диния нәзарәте рәисе, мөфти Талип хәзрәт Яруллин, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Иордания университеты профессоры шәех Габдерраззак әс-Сәгди, академик Энгель Таһиров, Әхмәдзәки хәзрәтнең оныгы Марат Сәфиуллин, Нурлат районы вәкилләре катнашты.

Чараны беренчеләрдән булып мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин ачып җибәрде. Мөфти Әхмәдзәки хәзрәтнең дин галиме буларак татар дөньясында тоткан урыны хакында җиткерде.

«Әлхәмдүлиллаһ, татар халкы арасында элек-электән чын рухи остазлар – ишаннар булган, – диде мөфти үз чыгышында. – Алар арасында хөрмәтле Әхмәдзәки хәзрәт Сәфиуллинның да исеме бар. Үсеп килүче буынны Әхмәдзәки хәзрәтнең хезмәтләре һәм фикерләре белән таныштыру – безнең изге бурычыбыз. Күренекле татар дин галимнәренең күбесе тәсаввуф традицияләре белән бәйле булган. Мәрҗани, Курсави, Утыз Имәни, Баруди, Рәмзи, Рәсүли, Ялчыгол шулар рәтендә. Суфичылык традицияләре дини сабырлыкка, тыйнаклыкка һәм бер-беренә хөрмәт күрсәтергә чакыра. Бу сыйфатлар иң мөһим әхлакый кыйммәтләр булып тора. Алар рухи тәрбия һәм игелек чыганаклары».

Камил хәзрәт Сәмигуллин Россиядә суфичылык бүгенге көндә дә актуаль булуына басым ясады, дини традицияләрне тергезүдәге проблемаларга туктап узды.

«Тәсаввуф – исламда иң мөһим фәннәрнең берсе. Тәсаввуфны өйрәнеп, кешеләр үзенеңэчкедөньясынямьләндерә һәм камилләштерә, холыкларын күркәм гадәтләр белән баета.



Бу фән Аллаһы Тәгаләнең колларын илаһи мәгърифәт белән бүләкли һәм шуның белән Раббыбызга якынайта. Суфичылык турында сөйләгәндә имам әл-Газали үзенең «Ихйа улум – əд-дин» китабында болай дигән: «Ахирәттә кешеләргә ярдәмгә дөньялыктагы байлыклар түгел, ә бары йөрәкләрендәге яктылык, гыйлем һәм ихласлык кына ярдәмгә килер», – диде мөфти.

Конференцияне дәвам итеп Әхмәдзәки хәзрәтнең якташлары чыгыш ясады. Араларында Нурлат районы мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов бар иде. Ул Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Сафа Таҗетдин исеменнән Әхмәдзәки хәзрәтне «Дан, намус һәм дәрәҗә» ордены белән бүләкләде һәм аны тантаналы төстә оныгы Марат Сәфиуллинга тапшырды.

Марат Сәфиуллин бабасының исемен йөрткән укуларның Татарстанда күркәм гадәткә кереп баруы өчен дин әһелләренә зур рәхмәтен белдерде.

«Бабамның нәсыйхәтләре, мирасы һәм тормыш юлы күпләр өчен үрнәк булуы мендә горурлык хисләре тудыра. Аның гыйлемгә хирыслыгы, булган белемен остазларча башкаларга җиткерергә тырышуы, мәгърифәти эшчәнлеге әле дә кызыксыну уята һәм хәзерге заман дин әһелләре өчен бер үрнәк булып тора. Бабам укучыларына җиткергән принциплар традицион ислам кыйммәтләренә туры килә һәм әле дә үзенең актуальлеген югалтмый», – дип белдерде хәзрәтнең оныгы Марат Сәфиуллин.

Сәламләү сүзләреннән соң фәнни эзләнүләре белән мөфти урынбасары Рәфыйк Мөхәммәтшин, БДБ илләре Институтының исламны өйрәнү бүлеге мөдире Илдар Сәфәргалиев, академик Индус Таһиров һәм Татарстанның мөселман уку йортлары мөгаллимнәре, җитәкчеләре бүлеште. Аерым алганда, конференциядә катнашучылар игътибарына Татарстанда дини традицияләрне тергезү проблемалары, интернетта суфыйчылык мәсьәләләрен яктырту һәм башка җитди темаларга чыгышлар тәкъдим ителде.

Сөйләшү ахырында резолюция кабул ителде. Конференциядә катнашучылар фикеренчә, чит агымнарга, экстремизм идеяларына киртә кую, яшь буынга динебезнең әхлакый принципларын җиткерү һәм рухи мирасыбызны саклап калу өчен түбәндәге тәкъдимнәрне гамәлгә ашырырга кирәк:

1. Мәдрәсәләр өчен тәсаувыф тарихы буенча дәреслек әзерләү;

2. Татар ишаннарының, имамнарының тормышларын һәм мирасын өйрәнү, алар турында китаплар бастыру, документаль фильмнар төшерү;

3. Борынгы кулъязмаларны өйрәнү, аларны хәзерге татар һәм рус телләренә тәрҗемә итү;

4. Мөгаллимнәр өчен Идел-Урал регионында тәсаувыф тарихы һәм мирасы буенча семинарлар, түгәрәк өстәлләр үткәрү;

5. III Әхмәдзәки хәзрәт Сәфиуллин укуларын Нурлат районының Кизләү авылында үткәрү;

6. Конференция материалларын китап рәвешендә бастыру.

# Камил хәзрәт Сәмигуллинның Татарстан мөселманнарының VII Корылтаенда ясаган чыгышы

**Бисмилләһир-рахманир рахим.**

**Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич!**

**Хөрмәтле Корылтай, Президиум, имамнар, килгән кунаклар!**

**Мөхтәрәм дин кардәшләрем!**

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән Диния нәзарәтенең җиденче Корылтаенда сезне сәламләргә рөхсәт итегез! Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллахи вә бәрәкатүһ!

Республика өммәтенең гаять мөһим булган вакыйгасында катнашырга вакыт һәм мөмкинлекләр тапканыгыз өчен тирән рәхмәтемне белдерәм. Аеруча, ерак араларны якын итеп килгән, авыл һәм районнарда дини эшләрне җигелеп алып баручы мөхтәсиб һәм имамнарга ихластан зур рәхмәт! Безнең шушындый күпсанлы составта бүгенгәчә очрашканыбыз юк иде әле. Бу алга таба матур бер күркәм гадәткә әйләнер дип өметләнәм.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем!

Хөрмәтле катнашучылар!

Россия Федерациясе – күпмилләтле дәүләтләрнең берсе. Татарстан да үз җирлегендә 170 милләт вәкилен сыендыра. Республикада бүгенге көндә 2 меңгә якын дини оешма эшли. Төрле конфессия вәкилләренең үзара ихтирамлы мөнәсәбәттә булулары республикабызның имин үсешен тәэмин итә. Татарстанда, диннәр төрле булуга карамастан, әхлакый кыйммәтләр һәм «кыйблалар» бөтен милләтләр өчен дә гомум.

Татарстан Россиянең башка субъектларыннан тагын бер уңай ягы белән аерылып тора – республика өммәте бердәм, ә мөфтият бердәнбер. Шул ук вакытта мәхәлләләр саны буенча безнең Нәзарәт Россия мөфтиятләре арасында беренче урында тора.

Форсаттан файдаланып, республика җитәкчелегенә, Президент Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов, беренче Президент Минтимер Шәрипович Шәймиевкә тирән рәхмәтемне җиткерәм. Татарстан өммәтенең done бербөтен булып сакланып калуында аларның өлеше зур.

Россия Президенты Владимир Путин да Исламның үсешендә соңгы елларда хәлиткеч роль уйнады. «Россиянең рухи даирәсе суверенитетын» булдыру өчен ул беренчел итеп түбәндәге мәсьәләләрне алга куя: Россия мөселманнарының дини гореф-гадәтләрен һәм мирасын торгызу, исламның иҗтимагый әһәмиятен үстерү, үзебезнең ислам динифәнни мәктәбен яңадан аякка бастыру һәм мөселман руханиларының абруен күтәрү.

Татарстан Диния нәзарәте оешканда да үз алдына шундый ук максатлар куйган иде. Ләкин тагын берничә бурычны үтәү дә зарури булды. Болар: дини оешмаларны берләштерү, аларның эшчәнлеген Коръән һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) сөннәтенә, имам Әбү Хәнифә юнәлешенә нигезләү һәм бердәй кануни үрнәккә китерү.

Шушы хисап чорында Нәзарәтнең эшчәнлегендә татар рухи мирасын торгызу идеясе «кызыл җеп» булып сузылды. Татарстан мөселманнарының тарихи хәтерен яңарту һәм бөек татар дин белгечләре исемнәрен мәңгеләштерү өчен, Шиһабетдин Мәрҗани, Татар дин галимнәре, Татар дини гореф-гадәтләрен торгызу, Хәнәфи мәзһәбе еллары игълан ителде. Өммәт яшәешен һәм эшчәнлеген тәэмин итәр өчен, Нәзарәттә тиешле идарә системасы булдырылды: голәмәләр шурасы, казыйлар шурасы, аксакаллар шурасы, казыятлар һәм мөхтәсибәтләр. Алар белән бергәлектә Нәзарәт хәзрәтләр һәм киң җәмәгатьчелектә шактый популярлык казанган «Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә» эшләп чыгарды.

Коръәнне өйрәнү мәсьәләсендә аерым тукталып үтәсе килә. 2016 елда Коръәннең «Каләм Шәриф» яңа басмасын бастырып чыгару Россия һәм бөтен дөнья мөселман өммәте тормышында әһәмиятле вакыйга булды. Моннан кала, без Россиядә беренче тапкыр Коръәннең тулы версиядәге аудиотасмасын да чыгардык. Бүгенге көндә Казанда һәм Татарстан районнарында 20дән артык Коръән түгәрәге булдырылды, «Рәшидә» үзәге һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Коръән өйрәнү факультеты ачылды.

Дини белем бирү өлкәсендәге казанышлар да игътибарга лаек. Мисал өчен, Татарстан Фәннәр академиясе, Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә Нәзарәт «Урта һөнәри дини белем бирү стандартлары»н әзерләде. Стандартлар 2015нче уку елыннан мәдрәсәләрдә кулланыла башлады.

Нәзарәт актив рәвештә социаль эшчәнлекне дә алып бара. Ул күбесенчә яшьләр, мигрантлар, тоткыннар һәм азат ителгәннәргә, ягъни радикаль көчләр йогынтысына аеруча бирелүчән төркемнәргә юнәлтелгән иде. Хисап чорында төрмәләрдәге мәхәлләләрдә хезмәт итү өчен имамнар сайланды. Шулай ук төзәтү колонияләрендә урнашкан китапханәләрне, традицион ислам турында әдәбият белән тулыландыруны да үз өстебезгә алдык.

«Зәкәт» фонды ярдәмендә Нәзарәт саваплы хәйрия эшчәнлеген дә алып бара. Фондның инициативасы белән 50гә якын авыру баланы дәвалау өчен акча түләнде.

Моннан тыш, нәзарәтнең халыкара элемтәләре һәм Россия регионнары белән бәйләнешләре үсешенең роле дә зурая бара. 2013-2017 елларда Диния нәзарәте делегацияләре чит төбәк һәм илләр чакыруы буенча 100дән артык рәсми сәфәр кылганнар. Нәзарәткә Берләшкән Милләтләр Оешмасы каршындагы консультант статусы бирелү буенча да эш тәгәлләнеп килә. Моннан тыш,



Россиянең динара советы составына кердек.

Алда әйтеп үтелгәннәрдән тыш, даими рәвештә ел саен үткәрелә торган, бөтен Россиягә дан казанган республика ифтары, Мәүлид ән-Нәби бәйрәме, Изге Болгар җыены кебек чаралар традицион Исламны популярлаштырырга һәм экстремизмга каршы торырга ярдәм итә. Һәм болар башкарган эшнең бер өлеше генә.

Хөрмәтле кунаклар!

2017 ел безнең өчен юбилей елы булып тора – 15 сентябрьдә Татарстанда Диния нәзарәте барлыкка килүгә 25 ел тула. Биредә утыручыларның күбесе үткән истәлекле вакыйгаларның шаһитлары булып кына калмыйча, аларда турыдан-туры катнашкан да әле. Безнең беренче мөфтиләребез – Габдулла хәзрәт Галиуллин, Госман хәзрәт Исхаков, Илдус хәзрәт Фәизовның исемнәре өммәтебез тарихына мәңгегә кереп калды.

Горурланырлык тарихың булганда, киләчәгең дә бар дигән сүз. Бүгенге заман мөселманы үзенең тормышын мәчеткә йөрү белән генә чикләми. Аның үз кызыксынулары бар, ул гаилә планлаштыру үзәкләренә, фитнеска, ресторанга, мәктәпләргә, балалар бакчаларына йөри... Шуңа күрә республикада мөселманнар өчен уңайлы мохит тудыруны максат итеп куйган «Тормыш рәвеше буларак ислам» дип аталган проект эшләнде һәм аны тормышка ашыра башларга вакыт җитте.

Моннан тыш, безнең алда өстенлекле булып түбәндәге мәсьәләләр дә торырга тиеш: татар дин галимнәренең хезмәтләрен өйрәнүне дәвам итү һәм укыту программаларына кертеп җибәрү; татар дини-фәнни мәктәбен торгызу; уку-укыту программаларын һәм материалларын стандартлаштыру; милли үзаңны һәм телне саклау; Коръәнне татар һәм рус телләренә кануни тәрҗемә итү.

Әлеге нәтиҗәләргә ирешү өчен, милләткә рухи-әхлакый юнәлеш бирә алырлык, тирән белемле татар дин белгечләрен һәм мөселман зыялыларын тәрбияләргә кирәк. Татарстан Республикасы ислам мәгарифе дәрәҗәсен үстермичә моңа ирешү һич мөмкин түгел.

Кызганычка, әлегә кадәр мөгаллимнәр арасында ислам һәм шәригать фәннәре буенча магистр яки фән докторы дәрәҗәсендәге белгечләр юк. Болгар ислам академиясен ачу бу мәсьәләне хәл итәр дип өметләнәбез. Бу – бер.

Ике. Имамнарның җәмгыятьтәге абруен күтәрмичә дә без максатларыбызга ирешә алмаячакбыз. Имамнарга һәм аларның ихтыяҗларына йөз белән борылырга, үз араларында һәм өммәттә теләктәшлек тәрбияләргә, хокукларын якларга кирәк, русча әйткәндә «корпоративная солидарность» дигән төшенчә кертергә кирәк.

Өч. Мөселман дин әһелләренең кадрлар резервын туплау. Бу өлкәдәге концептуаль документларны эшләүгә якын киләчәктә үк керешергә кирәк.

Дүртенчедән, зыялыларны әзерләү мәктәпләрдә үк башланырга тиеш. Бу уңайдан, «Госмания» хакында әйтеп үтми булмый. 100дән артык бала укуга карамастан, «Госмания»нең көнкүреш шартлары ифрат дәрәҗәдә начар хәлдә.

Белгәнебезчә, Россиядә өммәтнең эшчәнлеген җайга салу өчен Диния нәзарәте катнашында «Ислам һәм татар дөньясы» концепциясе һәм Россия мөселманнарының социаль доктринасы кебек программалы документлар кабул ителде. Әлеге документларга салынган нигезләмәләрне тормышка ашыру өчен, бездән билгеле бер чаралардан торган план эшләп чыгару таләп ителә.

Узган дүртъеллыкның мөһим казанышы булып тарихта беренче тапкыр Министрлар Кабинеты һәм үзәкләшкән дини оешмалар арасында, шул исәптән Диния нәзарәте белән дә, хезмәттәшлек турында килешүләр тора. Бу килешүләрне, күбрәк гомуми характерда булганга күрә, бүген конкрет тәкъдимнәрдән торган эчтәлек белән тулыландыру ихтыяҗы туды.

Алга таба – мәгълүмати сәясәт. Дөрес һәм уйлап корылган мәгълүмати сәясәт безгә киң җәмәгатьчелеккә Исламның асыл кыйммәтләрен җиткерергә, татар рухи мирасын сакларга, экстремизмга каршы торырга мөмкинлек бирәчәк. Хисап чорында «Хозур» нәшриятында дөньяга рус, татар һәм гарәп телләрендә 200дән артык китап чыкты, 200ләп видеоролик төшерелде һәм документаль фильмнар эшләнде. Имамнар өчен «Шура» журналы, рус телендә «Умма», татар телендә «Дин вә мәгыйшәт» газеталары чыга. «Ислам Today» интернет-порталы Россиянең иң популяр һәм абруйлы ислам хәбәрләре сайтына әйләнде.

Шуның белән беррәттән көнүзәк мәсьәлә булып хәзерге вакытка кадәр гомумроссия ислам телевизион каналын булдыру тора. Әлеге медиапроект рухи-әхлакый кыйммәтләрне, Россиядә яшәүче мөселман халыкларының милли мәдәниятен популярлаштырырга ярдәм итә алыр иде.

Гомумән, массакүләм мәгълүмат чараларына дини вакыйгаларны яктыртканда игътибарлырак булырга һәм һәр сүзне үлчәп язарга киңәш итәр идем. Бернинди дини нигезе булмаган көнкүреш конфликтларны кешеләрнең нинди диндә булулары белән бәйләү дөресме икән? Үзләре дә теләмәстән дип ышанасы килә, журналистлар җәмгыятебездә милләтара һәм динара киеренкелекне арттыра. Этноконфессиональ тематикага бәйле вакыйгаларны яктырту стандартларын эшләп чыгару артык булмас дип уйлыйм.

Дәвам итәм. Россиядә ислам үсешен хәләл индустриясеннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Татарстанда әлеге даирәне үстерүдә «Хәләл» стандартлары комитеты мөһим роль уйный.

Хәләл комитеты якын һәм ерак чит илләргә, Фарсы култыгына һәм Якын Көнчыгыш илләренә республикада җитештерелгән хәләл продукциянең экспортын үстерү максатыннан «Хәләл Агро Трейд» сәүдә йорты проектын тормышка ашырды. Медицина учреждениеләре өчен ислам кануннары буенча хезмәт күрсәтү стандартлары әзерләнде һәм гамәлгә кертелде.

Алга таба хәләл индустриясен үстерү максатында без хезмәттәшлекне шулай ук Икътисад, Сәнәгать һәм сәүдә, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек, Мәгариф һәм фән министрлыклары, Сәүдә-сәнәгать палатасы, Роспотребнадзор идарәсе, Туризм буенча Дәүләт Комитеты белән дә урнаштырырга кирәк дип саныйбыз.

Бүген Нәзарәтнең «Хәләл» Комитеты Россиядә олы абруй казанган оешма буларак билгеле. Шуңа карамастан, предприятиеләр еш кына төрле шикле консультантлар һәм сертификатлаштыру оешмаларына мөрәҗәгать итә. Алар исә сертификатны теләсә нәрсәгә бирергә әзер, хәтта сыраны хәләл дип билгели ала. Безнең Комитет исә сертификат биреп кенә калмыйча, җитештерүчеләргә ислам дөньясы вәкилләре белән профессиональ элемтәләр урнаштырырга ярдәм итә ала.

Вакф. Татарстан Республикасының Вакф фонды узган гасырларда мөселман өммәтенеке булып саналган күчемсез милекне кире кайтару белән уңышлы шөгыльләнә. Бу мәсьәләдә ведомстволар арасында эшлекле төркем булдырырга тәкъдим итәбез. Төркем кайтарырга тиешле дини милекнең исемлеген төзи һәм аны күчерү буенча планны эшләп чыгара ала.

Хаҗ оештыру. Шушы хисап чорында, «ДУМ РТ Хаҗ» хезмәтләреннән файдаланып, 7000нән артык мөселман хаҗ кылган. Ләкин, кызганычка каршы, безнең мөхтәсибәтләрдә көндәш оешмаларның агентлары хаҗ кылырга өндәп йөрүләре билгеле. Мәдрәсә директорлары, мөхтәсибләр һәм «ДУМ РТ Хаҗ»ның бер-берсе белән тыгызрак элемтәләр урнаштырып, әлеге мәсьәләне хәл итү юлларын тапса иде.

Сүземне йомгаклап, экстремизм һәм терроризм идеологиясенә каршы тору мәсьәләренә кагылмыйча булдыра алмыйм. Татарстан – күпсанлы мөселманнар яшәгән, икътисади яктан алга киткән республика. Икътисади үсешкә ирешкән субъектлар һәрвакыт радикаль көчләр өчен мишень булып тора. Чөнки, мондый регионнар, беренчедән, матди база буларак кабул ителә; икенчедән, күпсанлы мигрантлар арасында билгеле бер җимергеч сәясәт алып бару өчен уңайлы җирлек булып тора. Шуңа күрә безнең өчен әлеге тенденцияләргә каршы торырга һәм чит йогынтыга бирелми кала белү бик мөһим. Диннәр арасындагы яхшы һәм күркәм мөнәсәбәтләрне саклап калу киләчәктәге үсешнең һәм яшәешнең төп шарты булып тора.

Мөхтәрәм хезмәттәшләрем һәм килгән кунаклар!

Мин үз чыгышымда Диния нәзарәте алдында торган төп проблемаларны ачып бирергә тырыштым. Иманым камил: татар мөселманнары, үзенең гаять бай рухи мирасына һәм дини мәгариф системасының күп гасырлар дәвамында туплаган тәҗрибәсенә таянып, якындагы киләчәктә Россия рухи даирәсе үсешенә үзенең саллы өлешен кертәчәк әле. Татарстан Диния нәзарәте тырышлыгы белән ул бөтендөнья мөселман җәмгыятенең югары бәясен дә алыр әле, иншаАллаһ!

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

# Бу хатны укыгач, бөтен социаль челтәрләрдән чыгарга булдым

*Дәвамы. Башы 1нче биттә*

Мин яңа телефоныма төрле кушымталар урнаштырырга тотындым. Күңелемә иң хуш килгәне Whatsapp булды. Әти-әниемә, Америкада яшәүче сеңлемә балаларымның фотоларын җибәрдем. Дусларымны өстәдем.

Whatsapp мине шул дәрәҗәдә үзгәртте, мин иремә, балаларыма, өйдәге вазыйфаларыма битараф була башладым. «Бу миңа кагылмый», – дип кенә җибәрә идем. Яңа дуслар таптым, элек аралашкан танышларым белән элемтәләрне яңарттым.



Телефоннан башка яши алмас дәрәҗәгә җиттем. Элек балаларым белән уйный, китаплар укый, урамга чыгып йөри торган идек – көнемне дә, төнемне дә смартфонда үткәрергә тотындым. Иртәнге өчләргә кадәр дус кызларым белән язышып чыга идем.

Узган айның дүртесендә, мин иптәш кызым белән телефоннан сөйләшеп утырганда, күрше бүлмәдән улымның: «Әни! Әни!» – дип ачыргаланып кычкыруын ишеттем. «Авызыңны яп, мин телефоннан сөйләшәм», – дип кенә җаваплыдым мин аңа. Күңелем шул буш сөйләшүдә иде.

Шуннан соң Мөхәммәд мине башка борчымады. Ун минуттан күрше бүлмәгә керсәм, кызымның идәндә хәрәкәтсез ятуын, ә улымның аның янында елап утыруын күрдем.

– Нәрсә булды? – дип кычкырдым мин.

– Әнием, мин сине чакырдым – син миңа тавышланмаска куштың. Әдилә нәрсәдер йотты. Сулый алмады. Мин ул әйберне чыгара алмадым...

Мин улымны җилкәләреннән селкергә тотындым... «Ашыгыч ярдәм» чакырттым. Табиблар берничә минуттан килеп җитте, әмма инде соң иде.Шуннан соң полиция килде. Миннән сорау алырга тотындылар. Үлем сәбәбен ачыклау өчен Әдиләне хастаханәгә алып киттеләр...

Хастаханәдә ирем барысын да сораша башлады. Әдиләбезне югалтуга ышана алмый иде ул. Мин нәрсәләрдер уйлап чыгарырга тотындым, акланырга тырыштым. Гаиләбезне саклап каласым килде, иремне югалтырга теләмәдем. Ләкин ул алдавымны аңлады һәм дөресен сөйләргә боерды.

Фаҗиганең ничек килеп чыгуын сөйләп бирдем. Ирем бик каты ярсыды, күзләремә карап: «Талак! Талак! Талак!» – дип кычкырды да, күз яшьләрен тыя алмыйча, чыгып китте.

Мин бер мизгелдә барысын да югалттым. Кызыбыз үлде. Ирем аерып җибәрде. Улыбызны да үзе белән алып китте. Миңа хастаханәдә дәваланып чыгарга туры килде. Бер акылсызлык аркасында бәхетле тормышымны җимердем.

Мөслимә кардәшләремә бу вакыйга гыйбрәт булсын иде. Телефон, интернет, социаль челтәрләр, юк-бар сөйләшүләр аркасында өегезне, гаиләгезне, ирегезне, балаларыгызны онытмагыз.

Миңа хәзер бик авыр. Раббымнан сабырлык сорыйм...

Без хәзер башка.

Аллаһы Тәгаләне зикер итмибез, Коръән укымыйбыз.

Намазларыбызны калдырабыз.

Буш вакытыбызны телефон белән интернетка сарыф итәбез.

Үз-үзебезгә сорау бирик әле: социаль челтәрләр безгә нәрсә өчен кирәк? Файдагамы алар, зыянгамы? Дус-туганнарыбызның хәл-әхвәлен белешәбезме без анда, әллә башкаларның ничек яшәвен тикшерәбезме? Берәр мохтаҗны табып, аңа ярдәм итәргә тырышабызмы, әллә файдасыз, хәтта зыянлы әйберләр карыйбызмы?

Телефон, интернет, социаль челтәрләр гомеребезнең кадерле мизгелләрен урлый. Без замана казанышларыннан файдаланабызмы, әллә алар безне читлеккә бикләп куйдымы?

Йә Раббым! Безне туры юлга күндер!

Аллаһтан башка көч-кодрәт юк.

**ИСЛАМ ТАРИХЫ**

# Сәхабәләр ачуланышкан чакта да кардәшлекне онытмаган

Риваять ителгәнчә, Могавия сәхабәнең эшчеләре Гали ибне Әбү Талипның (Аллаһ алардан разый булсын) бакчасына кергәннәр һәм үзләреннән соң җыештырмыйча чыгып киткәннәр. Бакча бик ямьсез хәлдә калган. Сүз уңаеннан, күршедә яшәүче бу ике сәхабәнең бакчалары арасында бернинди рәшәткә дә булмаган – туганнар да ике арада биек койма корган чорда яшәүчеләр өчен чын кардәшлекнең бер мисалы бу.

Гали, бакчасы нинди кыяфәткә килгәнен күргәч, Могавиягә хат язган:

«И Могавия, хактыр, синең эшчеләрең чиктән ашты. Минем бакчама кереп, бөтен әйберне ватып, артларыннан җыештырмыйча чыгып киткәннәр».

Могавия, хатны укыгач, кәгазь битенең икенче ягында болай дип җавап кайтарган:

«Хактыр, минем бакчам хәзер синеке, мин аны сиңа бүләк итәм».



Хат Галигә әйләнеп кайткач, Гали еларга тотынган...

Бүген мөселманнар вак кына сәбәп өчен дә тарткалашырга, сугышырга, бер-берсен кимсетергә генә тора. Әшәке сүзләр әйтешеп, шуны ирлеккә санап, үзләре дә кимсетәләр, кардәшләрен дә рәнҗетәләр, мөселманлыкның да дәрәҗәсен төшерәләр.

Аллаһ Раббыбыз һәрберебезгә холык-фигыльләребезне камилләштерергә ярдәм итсен.

АВЫЛ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

**18 март көнне Аксубай районы Түбән татар Майнасы авылында «Көнбатыш Кама аръягы торак пунктлары тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү проблемалары» исемле төбәк фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Әлеге фәнни чарада йөздән артык вәкил катнашты.**



Алар арасында Татарстан фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Альфред Халиков исемендәге Археология институты галимнәре Альберт Борһанов, Дамир Исхаков, Фаяз Хуҗин, Наил Нәбиуллин һ.б., шулай ук Кама аръягының төрле районнарыннан килгән туган якны өйрәнүчеләр, тарихчылар, укытучылар бар иде.

Конференциядә АКШның Висконсинск университеты профессоры, тарих фәннәре докторы Юлай Шамилуглының да чыгыш ясавы әлеге чараны халыкара дәрәҗәгә күтәрде.

Язучы, тарих фәннәре кандидаты Ф. Бәйрәмованың борынгы Биләр каласы турындагы ялкынлы чыгышы, «ТАТАРГЕН» проекты җитәкчесе Максум Акчуринның доклады да конференциядә катнашучыларны битараф калдырмады.

Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән авыллар тарихын өйрәнеп китап чыгаручыларга рәхмәт хатлары тапшырды.

Конференцияне оештыручы – Түбән татар Майнасы урта мәктәбе директоры, тарих фәннәре кандидаты, 17-18 йөзләрдәге Кама аръягы авыллары тарихын өйрәнгән галим Рәфыйк Насыйров.

Аның фикеренчә, әлеге чараның төп максаты – кечкенә авыл кысаларында да шундый күләмле чаралар үткәрә алу мөмкинлеген күрсәтү. «Фәнни-гамәли конференцияләр, гадәттә, шәһәрләрдә оештырыла. Үзебезнең мисалда башкаларга да, галимнәр чакырып, авыл шартларында фәнни эшчәнлек алып бару мөмкинлеген күрсәтергә теләдек. Безнең авыл кечкенә, ул беркайчан да зур булмаган. Шулай да аның тарихы бик бай һәм борынгы. Күпме генә өйрәнсәм дә, яңа кызыклы фактлар чыгып тора», – ди ул.

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк: Түбән Майна авылында мәктәп һәм балалар бакчасы бинасы 2014 елда район җитәкчелеге һәм авыл халкы ярдәме белән төзелде. Бу эштә дә башлап йөрүче Рәфыйк Насыйров булды.

Конференция югары дәрәҗәдә оештырылган иде.

Моннан һәркем рухи канәгатьләнү, иҗади дәрт алып китте. Төбәк тарихын өйрәнү дәвамлы булсын, авылларда да мондый чаралар ешрак үткәрелсен иде.

**ГҮЗӘЛ БАТЫРШИНА**

# Татар вәгазь теле үзенчәлекләре

**Хөтбә-вәгазь өслүбендә кулланыла торган лексик берәмлекләрне үзләренең килеп чыгышлары буенча, асылда, өч зур төркемгә берләштерергә мөмкин:**

1. Төрки-татар сүзләре.
2. Гарәп-фарсы алынмалары.
3. Рус һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр.

Дөрес, вакытлар узу белән, төрки-татар сүзләренең дә кайберләре киң кулланылыштан төшеп калалар, телнең архаик катламына күчәләр. Алар арасында мәгънәви үзгәрешләр кичергәннәре дә шактый. Телнең пассив сүзлек составына күчсәләр дә, аерым стильләрдә аларның шактый еш кулланылганлыклары күзәтелә.

X гасырга чаклы ук Идел буе Болгар дәүләтендә гарәп язуына һәм теленә өйрәткәннәр. X йөз башында ислам дине кабул ителгәннән соң, Якын Көнчыгыш белән бәйләнешләр тагын да көчәйгән, телебезгә аеруча дини төшенчәләрне белдергән бик күп сүзләр, гыйбарәләр кабул ителгән.

XIII-XIV гасырларда, бигрәк тә XVIII-XIX гасырларда татар теленә үтеп кергән бик күп гарәп-фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре башта язма телдә, соңга таба халыкның сөйләм телендә дә кулланыла башлаган. Әмма бу алынмаларның билгеле бер өлеше сөйләм теленә үтеп керсә дә, язма әсәрләрдә киңрәк файдаланылган. Шуның нәтиҗәсендә халыкның сөйләм теленнән шактый аерылып торган югары стильдәге китап теле барлыкка килгән.

XIX йөзнең соңгы чирегендә милли әдәби телне формалаштыру, гарәп-фарсы сүзләре белән тәмам чуарланган, аңлаешсызга әверелгән китап телен халыкның сөйләм теленә якынайту буенча киңкырлы эшчәнлек башлана.

Хөтбә-вәгазьләр лексикасында гарәп-фарсы сүзләре актив кулланылышка ия, ягъни алар бу өслүбнең шактый бай сүзлек составын тәшкил итәләр. Аларның киң кулланылышы, аеруча, дини вәгазьләрдә күренә. Бу аңлашыла да, чөнки Коръән аятьләренә, Мөхәммәд (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) сөннәтләренә, дини риваятьләргә нигезләнгән вәгазьләрдә башкача була да алмый. Шуңа күрә хөтбә-вәгазьләрдә файдаланыла торган барлык гарәп-фарсы сүзләрен һәм гыйбарәләрен ике зур төркемгә бүлеп карый алабыз.



1. Дини төшенчәләрне белдерә торган лексика.
2. Иҗтимагый тормышның төрле өлкәләренә караган сүзләр.

Кайбер вәгазьнамәләрдә бүгенге көн укучысы өчен аңлашылмаган аерым сүзләргә шәрехләүләр бирелсә дә, шактый гына гыйбарәләр аңлаешсыз кала. Гарәпчәләре камил, исламияттән гыйлемнәре житәрлек булмаган кешеләргә, һичшиксез, аларның мәгънәләренә төшенү авыррак.

Әлбәттә, хөтбә-вәгазьләр телендә кулланылган барлык гарәп-фарсы сүзләренә аңлатмалар биреп бетерү мөмкин эш түгел. Дини төшенчәләрне белдергән барлык атамаларның татар телендәге бердәйлекләрен дә табу читенрәк. Әмма телебездә андый мөмкинлекләр дә җитәрлек, бигрәк тә, архаик катламда булган алынмаларны шәрехләгәндә. Шуңа күрә гарәпчәдән һәм татарчадан шактый гыйлеме булган имам-хатыйб хәзерге татар әдәби теленең мондый лексик җегәрлеген дә истән чыгармаска тиешле.

Билгеле булганча, телебезнең сүзлек хәзинәсендә ныклы урын алган гарәп-фарсы сүзләренең иң зур күпчелеге гасырлар дәвамында кулланылып килү нәтиҗәсендә бөтенләй диярлек «татарлашып» беткән, һәм гарәп телен белмәүчеләр аларны ана теле сүзләре дип тә уйлыйлар.

**НИЯЗ САБИРҖАНОВ**

КИҢӘШЛӘР

# Мөселман кешесенә тиешле булган 10 сыйфат

**Аллаһы Тәгалә безгә Изге Китабын тормышыбызның төп кулланмасы итеп җибәргән. Коръәнгә таянып яшәгән кеше генә, ике дөнья бәхетенә һәм Аллаһ ризалыгына ирешә, Коръәнне калдырганнар – Аллаһны калдыручылар. Аллаһ китабында мөселман кешесенең холкында булырга тиешле күркәм сыйфатлар безнең өчен нәсыйхәт булып торалар:**

1. Шәфкатьле булу.

«Ий Мөхәммәд (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм), Аллаһның рәхмәте белән өммәтеңә шәфкатьле булдың, әгәр каты күңелле булсаң, әлбәттә, синең тирәңнән качар иделәр. Сәхабәләренең хата эшләрен гафу ит һәм алар өчен Аллаһыдан ярлыкауны сора һәм дә зур эш булганда алар белән киңәш ит! Әгәр бер хәерле эшне ниятләсәң, Аллаһыга тәвәккәл итеп ниятләгән эшеңне эшлә, киңәшкә алданып буш калма! Аллаһ, әлбәттә, үзенә тәвәккәл итүчеләрне сөядер» (3:159).

2. Ачуны йота белү.

«Ул мөэминнәр бай чакларында да, ярлы чакларында да Аллаһ күрсәткән урыннарга сәдака бирәләр, ачулары килгәндә ачуны йоталар, гаепле кешеләр гафу сораганда гафу итәләр. Яхшылык кылучы әнә шундый мөэминнәрне Аллаһ сөядер» (3:134).

3. Башкаларга карата яхшылык кылу. «Аллаһының үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары: ата-анага изгелек итегез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган күршеләргә һәм кардәш булмаган күршеләргә дә изгелек итегез. Шулай ук сәфәрдә ят юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһ, әлбәттә, сөйми!» (4:36).

4. Гафу итә белү.

«Ий Мөхәммәд (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм)! Синең эшең гафу сораучыларны гафу итү булсын вә яхшылыкка өндәү булсын! Һәм хакны аңламаучы җаһилләрдәннаданнардан кисел, алар белән булышма!» (7:199).

5. Йомшаклык күрсәтү.

«Аңа йомшак яхшы сүзләр сөйләгез шаять вәгазьләнер яки Аллаһ газабыннан куркыр» (20:44).

6. Кешеләрне кимсетмәү.

«Ий мөэминнәр, бер кавем икенче бер кавемне кимсетмәсен, ул кимсетелгән кавемнең кимсетүче кавемнән яхшырак булуы ихтималдыр, шулай ук хатыннар икенче хатыннарны кимсетмәсеннәр, кимсетелгән хатын кимсетүче хатыннан яхшырак булуы ихтималдыр, вә дин



кардәшләрегезне гаепләп кимсетмәгез, вә бер-берегезгә яман кушым исемнәр илә дәшмәгез, мөэмин булганнан соң, фасыйк исеме ни яман исемдер. Бу эшне эшләүчеләр тәүбә итеп төзәлмәсәләр, алар залимнәрдер» (49:11).

7. Ата-анага яхшылык кылу.

«Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф" та димәгел, вә каһәрләмә кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйләгел!» (17:23).

8. Бурычлы кешеләрнең хәлен җиңеләйтү.

«Әгәр сездән бурычка алган кешеләр бурычларын түли алмаслык фәкыйрь булсалар, бурычларын түләргә мал тапканнарына чаклы кичектерү сезгә лаземдыр. Әгәр бурычларын түләргә көче җитмәгән кешеләргә, бурычларын үзләренә сәдака кылсагыз, сезнең өчен бик тә хәерледер, әгәр белсәгез!» (2:280).

9. Ришвәт бирмәү.

«Малларыгызны үз арагызда хыянәт юлы белән ашамагыз, һәм кешеләрнең малларын хөкем аркылы золымлык белән алыр өчен казыйлар, хөкемдарлар алдына малыгызны салмагыз – ришвәт бирмәгез! Үзегез беләсез бу эшнең золым икәнен» (2:188).

10. Юмартлык күрсәтү, сабыр булу, сүздә тору.

«Ий мөшрикләр, кояш чыга торган якка һәм кояш бата торган якка юнәлеп табынуларыгыз Аллаһы хозурында изгелек түгел. Ләкин берәү Аллаһыга, ахирәт көненә, фәрештәләргә, китапларга һәм пәйгамбәрләргә иман китереп үзенә кадерле малыннан мохтаҗ булган якын кардәшләренә, ятимнәргә, мескеннәргә, мөсафирләргә, мохтаҗлыктан ярдәм сораучыларга һәм колларны азат итү юлына сәдакалар бирсә шулай ук зәкәт, гошер сәдакаларын бирсә, намазларын вакытында үтәсә, янә Аллаһыга биргән гәһден, кешеләргә биргән вәгъдәсен үтәсә, янә ярлы вакытта нинди булса да бәла-каза ирешкәндә, ачлык яки сугыш килгәндә сабыр итсә Аллаһыга чыдамлылык күрсәтсә, әнә шул эшләр изгелекләр. Шул эшләрне эшләүче мөэминнәр иманда һәм диндә дөрес эш кылучылар һәм алар Аллаһыдан куркучы тәкъва кешеләрдер» (2:177).

**НУРИЯ САБЫРҖАН**

# Пәйгамбәребезгә (салләллаһу галәйһи вәссәлам) мәхәббәт яки «Шәл турында поэма»

**Ий Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) әйт: «Әгәр Аллаһыны сөяр булсагыз миңа иярегез, миңа иярсәгез Аллаһ сезне сөяр һәм гонаһларыгызны ярлыкар. Тәүбә итеп, Аллаһ юлына керсәгез, Ул, әлбәттә, ярлыкаучы һәм рәхимле». (Коръәни Кәрим, 3:31)**

Рабигыләүвәл аенда мөселманнар Мәүлид бәйрәмен – Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлам) туган көнен Коръәни Кәрим сүрәләрен укып, Аллаһы Тәгаләгә зикер әйтеп, Пәйгамбәребезгә (салләллаһу галәйһи вәссәлам) салаватлар укып, билгеләп үтәләр. Мөселманнар Аллаһы Тәгалә Илчесен (салләллаһу галәйһи вәссәлам) башка көннәрдә дә искә алалар һәм моның өчен савабын да алалар. Хәдисләрнең берсендә болай диелә: «Җәннәткә Аллаһы Тәгаләне яратучылар, Аллаһы Тәгаләне яратучыларны яратучылар һәм Аллаһы Тәгалә күрә алмаганнарны күрә алмаучылар керәчәк». Аллаһы Тәгаләне Аның өчен ярату – Аның үзен ярату дигән сүз. Имам Бусайриның «Бурда» Касыйдәсе Аллаһы Тәгалә Илчесенә (салләллаһу галәйһи вәссәлам) карата булган тирән мәхәббәткә багышланган.

Имам Салих Шәрәфетдин Әбү Габдулла Мөхәммәт Бин Хәсән Әл-Бусайри хәзрәт һиҗри ел исәбе буенча 7нче гасырның танылган шагыйре була. Ул хиҗри ел исәбе буенча 608 елда, милади ел исәбе буенча 1213 елда Әбусайрада туа. Имам Салих Шәрәфетдин ун ел Иерусалимда яши, соңрак 13 елга Мәккәгә күчә, анда Коръәни-Кәримне укырга өйрәтә, танылган нәккашь була, югары урын тота. Мисырда аның касыйдәләре бастырыла, араларында иң танылганнары – «Хәмзия» касыйдәсе һәм «Бурда» касыйдәсе. «Бурда» касыйдәсе күп кенә телләргә тәрҗемә ителә, шул исәптән, урду, латин, инглиз, француз һәм рус телләренә дә. Имам Салих Шәрәфетдин 694 елда Мисырда, Александриядә үлә.

«Бурда» касыйдәсе язылуы Имам Салих Шәрәфетдин белән булган бәхетсез очракка бәйле. Бу вакытта ул ислам галиме һәм мәгърифәтчесе Әбүл Габбас Әхмәд Әл-Мурси шәкерте була һәм хәдисләр буенча тирән белемнәр ала. Ләкин бу вакытта имам Салих Шәрәфетдингә паралич суга һәм аның ярты гәүдәсе селкенмәскә әйләнә. Шул хәлдә ул Аллаһы Тәгаләдән догаларында Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлам) бөеклеген күрсәткән поэма язарга илһам бирүен һәм поэмага фатыйхасын бирү аша параличтан терелтүен сорый. Аллаһы Тәгалә аның догаларын кабул итә. Поэмада Имам үз хисләрен һәм фикерләрен бик тәгәл һәм матур итеп тасвирлый.

Пәнҗешәмбедән җомгага булган төнне ул поэманың соңгы бүлеген тәмамлап, Аллаһы Тәгаләгә зикер итә башлый. Шуннан соң ул поэманы укый башлый да, йокыга китә, төшендә Пәйгамбәребезне (салләллаһу галәйһи вәссәлам) күрә. Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлам) кулы белән Имамның гәүдәсе буенча йөртеп чыга. Бу кагылу аша Аллаһы Тәгалә Имамны тулысынча параличтан терелтә. Уянганда Имам Бусайри кулында Аллаһы Тәгалә Илчесе аның паралич суккан әгъзаларына салган шәлне тота. «Бурда» касыйдәсе («Шәл турында поэма») шулай языла.

Поэманың кыскача эчтәлеген һәм иң тәэсирле җөмләләрен карап үтик.

**1нче бүлек**

Ике дөнья өчен дә иң яхшы булган күренеш – Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәссәлам), әә бөтен кешелек өчен булган иң зур бүләк – аның шәфәгате, Кыямәт Көненең каты сынауларыннан бөтенесен дә яклау хакы. Аллаһы Тәгалә үзенең яраткан Пәйгамбәрен (салләллаһу галәйһи вәссәлам) искиткеч зур рухи тормыш белеме белән бүләкли, шул исәптән бу һәм теге дөнья тормышы турындагы белем белән, Үзе һәм Сыйфатлары турындагы белем белән.

– «Шулай итеп, яшь кан белән кушылып (күзләрдән) ага» авторның Ислам диненә һәм Пәйгамбәребезгә (салләллаһу галәйһи вәссәлам) булган зур мәхәббәтеннән.

– «Күзләрең белән нәрсә булды соң, син сөйләгән саен алар күбрәк яшь түгәләр».

– «Йөрәгең белән нәрсә булды соң, син аны тынычландырган саен, ул күбрәк тынычсызлана».

– «Аның күзләре яшь түккәндә һәм йөрәге кызганда».

– «Синең яңакларың сары роза-лар һәм кызаручы агач кебек».

– «Шатлык та сызлануга әверелә». Авторның йөрәгендә булган мәхәббәтне котрольдә тотарга көче юк. «Мәхәббәт минем ихтыярымнан башка бирелгән».

– «Бу искиткеч зур мәхәббәт сызлану китерсә дә, автор аның туктавын теләми».

– «Хакыйкать, саф мәхәббәт кешене башка нәрсәләргә карата саңгырау итә».

**2нче бүлек**

Автор кешеләрне тән дәртенә бирелүдән һәм түбән теләкләрдән кисәтә. Ул чын күңелдән кылган гөнаһларына үкенә, Аллаһы Тәгаләдән гафу итүен сорый. Аллаһы Тәгалә Илчесе Мөхәммәдне (салләллаһу галәйһи вәссәлам) чын күңелдән яратырга теләгән һәм аның галәмнәр өчен шәфкать булуын бәяләргә теләгән кешегә үз нәфесенә бирелмәскә мөһим.

**3нче бүлек**

Автор Аллаһы Тәгалә Илчесе Мөхәммәднең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) сыйфатлары һәм холкының камиллеге турында сөйли, Аллаһы Тәгаләнең аңа карата булган чиксез мәхәббәтен ассызыклый. Коръәни-Кәримнең «Әл-Әзхаб» сүрәсенең 56нчы аятендә Аллаһы Тәгалә мөселманнарны Үзенең яраткан бәндәсенә мәхәббәтләрен ныгыту өчен салават укырга өнди.



– Мин сөннәтне бозгаладым, Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлам) сөннәтен үтәүдә тотрыклылык күрсәтмәдем, Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлам) төннәрен гыйбадәт кылып үткәргән, һәм бу бөек сөннәт! Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) төнлә кылган намазлары озын һәм камил булганнар. Бу гыйбадәт шул дәрәҗәдә киеренке булган ки, гөнаһсыз Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) аякларын көзән җыерган, алар намазда озак тору сәбәпле сызлый башлаганнар.

– Аллаһы Тәгаләнең яраткан бәндәсе булып та, Аның Илчесе (салләллаһу галәйһи вәссәлам) Ислам өчен акылга сыймаслык кыенлыклар һәм фәкыйрьлек аша узган. Кайвакыт ул берничә көн, хәтта ай да су һәм хөрмә җимешен генә ашаган. Ашыйсы килүенә түзә алмыйча, ачлык хисен бетерү өчен корсагына бер яки ике таш бәйли торган булган. Җәбраил фәрештәнең Аллаһы Тәгалә аның өчен Мәдинә тауларын алтынга әверелдерүен тәкъдим иткәч, Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәссәлам) тыйнаклыгы, батырлыгы, мохтаҗлыкны ярату һәм зур ихтыяр көче булуы аркасында тәкъдимгә кызыкмый һәм аны кире кага. Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) тәкъвалыгы мохтаҗлыкка, фәкыйрьлеккә һәм ачлыгына карамыйча, көчәя генә. Аның диндарлыгы фәкыйрьлеге белән арта гына бара. Һәм бу барысы да Аллаһы Тәгаләнең аның иң яхшы бәндәсе – Пәйгамбәребез Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) өчен бу галәмне булдыруына карамастан.

**4нче бүлек**

Аллаһы Тәгалә Илчесе туган төнне фарсылар патшасы Кисраның сарай диварлары ишелә. Зоратустра уты сүнә. Җеннәр Аллаһы Тәгалә Илчесен (салләллаһу галәйһи вәссәлам) күрүгә кычкара башлыйлар, нур балкый башлый. Худжун һәм Әбү Кубайс тауларында Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәссәлам) туган вакытта нур күренә. Пәйгамбәрлек хакыйкате шул нур һәм тавышлар белән барлыкка килә. Фәрештәләр ут белән куганга күрә, җен һәм шайтаннар качалар.

– Качучы җеннәр кебек үк, Кәгъбәтулланы җимерергә теләгән Йәмендәгы хәбәш патша Абраханың сугышчан филле гаскәрләре дә кычкыра. Аллаһы Тәгалә Абраханың гаскәрләрен җиңү өчен томшыкларына таш тоткан кошларны җибәрә. Бу ташлар белән кыйналу Абраханы һәм аның гаскәрен котларын ала һәм качарга мәҗбүр итә. Ул елны «Фил елы» дип атыйлар.

– Бәдр сугышында Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәссәлам) тәсбихтан соң бер уч комны дошман гаскәренә таба ыргыта һәм аларның күзләрен сукырайта.

**5нче бүлек**

Автор сүзләре буенча, Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) төп максаты – кешеләрне Аллаһы Тәгаләгә чакыру.

**6нчы бүлек**

Автор Коръәни-Кәрим могҗизалары турында яза. Һәр пәйгамбәргә вакытлыча билгеле бер могҗизалар бирелгән. Ул могҗизаларны замандашлары гына дәлилли алганнар, ә Коръәни Кәрим – мәңгелек могҗиза, аны бөтен заман кешеләре дә дәлилли алалар. Аны мөмкин кадәр ешрак укырга һәм анда бирелгән кануннар буенча яшәргә кирәк.

**7нче бүлек**

Автор Аллаһы Тәгалә Илчесенең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) күкнең Җиденче катына «Мигъраж» итүе. Бу сәяхәтендә Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) Сидратуль-Мунтаханы кичә, Аллаһы Тәгалә аны беркемне дә моңа кадәр якын китермәгән җиргә ала. Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вәссәлам) башка җан ияләреннән күпкә югарырак баскычта була.

**8нче бүлек**

Мигъражка кадәр Пәйгамбәребез Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) сәхәбәләре белән Мәккәдә яши.

Пәйгамбәрлекнең 13нче елында Аллаһы Тәгалә аларга хиҗрәт кылырга куша – Мәдингә күчәргә. Автор Аллаһы Тәгалә Илчесенең җиһадын, аның Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәлләвен, батырлыгын, гамәлләрен һәм Ислам хакына үзен корбан итәргә әзерлеген тасвирлый.

**9нчы бүлек**

Автор Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) пәйгамбәр яклавы һәм шәфәгате аша Аллаһы Тәгаләдән гөнаһларын кичерүен өмет итә, кылган гөнаһларына һәм хаталарына үкенә. Аллаһы Тәгаләдән тәүбәсен кабул итүен үтенә. Автор бу касыйда аша Кыямәт Көнендә Пәйгамбәребез яклавына ирешергә өметләнә.

**10нчы бүлек**

Автор Аллаһы Тәгаләнең яраткан бәндәсе – Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) пәйгамбәргә булган мәхәббәтендә үзенә яклау эзли. Ул Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлам) яклавы аша котылырга өметләнә.

Автор шулай ук тормышын, мәхәббәтен Аллаһы Тәгаләгә һәм Мөхәммәт (салләллаһу галәйһи вәссәлам) пәйгамбәргә багышларга җыена.

Поэма Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) пәйгамбәргә, аның гаиләсенә, дүрт гадел хәлифәгә салават һәм сәлам белән тәмамлана. Автор Аллаһы Тәгаләдән үзен һәм бу поэманы укучыларны кичерүен сорый.

**ХӘСӘН ХӨСӘЕНОВ**

# АКТУАЛЬ СОРАУЛАРГА ХӘНӘФИ МӘЗҺӘБЕ БУЕНЧА ҖАВАПЛАР

**– Мин терлекчелектә эшлим, эш бик зәһәр исле, кайткач ванна кереп, 2-3 кат юынмыйча, тәндәге ис бетми. Ураза вакытында миңа нинди киңәш бирерсез икән: ураза тотарга буламы?**

– Ураза вакытында кешенең эшли торган эше пычрак эш булса, нәҗесе беткәнче яхшылап юынырга кирәк, әгәр пычраклары нәҗессез булса, юыну мәҗбүри түгел, авыз ачкач яхшылап юынырга мөмкин. Ис бетәрлек кадәр бервакытта да юынып булмый, ис бетмәсә дә ярый, ләкин тәндәге нәҗесләрне бетеру өчен госел коенырга кирәк. Өстән су сибеп юыну уразаны бозмый, ә суга кереп утырып юыну, мәсәлән, ваннага чумып юыну уразаны боза. Исләр уразаны, шулай ук, бозмый. Димәк, терлекчелектә эшләүчеләргә ураза тотарга мөмкин.

**– Рамазан аенда ураза тоту өчен мөселманча суйган ит кирәк, диләр. Шәһәрдә мөселманча суйган ит таба алмаганда, базар ите ашап ураза тотсак, тоткан уразабыз кабул булыр микән? Авыз ачтырырга да үзең суйган ит кирәк, диләр. Мөселманча суйган ит ала алмасаң, нәрсә белән авыз ачтырырга?**

– Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) үзе яшәгән заманда сәхабәләргә Рамазан аенда ураза тотучы кешеләрне мәҗлескә җыеп авыз ачтырырга куша. «Авыз ачтырган кеше, – ди ул, – муенын җәһәннәм газабыннан коткарыр, Аллаһы Тәгалә аның белеп һәм белми кылган гөнаһларын ярлыкар. Ураза тоткан берәр кешегә авыз ачарга бер хөрмә яисә баллы су биргән, аны ризыкландырган кешегә Аллаһы Тәгалә ураза тоту савапларын бирер, сусаганга эчерүчене гарасат мәйданына чакырмас», – дигән. Аны (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) тыңлап торган сәхабәләр: «Авыз ачтырырга хәлебездән килми бит», – диләр. Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) аларга сөт ризыклары белән авыз ачтытырырга мөмкин икәнлеген әйтә.

Сез яшәгән шәһәрдә мөселманча суелган итләр сатылмый икән, борчылмагыз. Ит кенә түгел, сөт ризыклары белән туклану да хәләл бит. Сөтле аш базардан ничек итеп суелганын да белми торып сатып алынган иттән пешерелгән ашка караганда хәерлерәк санала.

**– Ураза тотарга ниятләүне кычкырып әйтергә кирәкме, әллә күңелдән генә хәл итәргәме?**

– Күңел белән, уй белән ураза тотарга ниятләү – җитәрлек шарт. Ниятләүне тел белән әйтү дә яхшы, ләкин мәҗбүри түгел. Таң атканчы ниятләргә кирәк, яки кояш батканнан соң, кичтән үк ниятләп куярга да ярый. Аллаһы Тәгаләнең соңгы илчесе Мөхәммәд (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) әйтүенчә, таң атканнан соң ниятләнгән ураза дөрес булмый.

Дүрт мәзһәбнең өчесенең дин әһелләре ниятләүне көн саен кабатларга кирәк дип саный. Ә Мәлики мәзһәбе галимнәре ниятләүне бары бер генә тапкыр, Рамазан ае башланганда гына үтәү дә җитә дип уйлыйлар.

**– Авыз ачу мәҗлесендә 9 кешедән дә ким кунак булмаска тиеш. Кеше азрак җыелса, авыз ачтыру дөрес булмый, дип раслаучылар бар шәһәребездә. Мондый таләп урынлымы?**

– Пәйгамбәр (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) авыз ачтыру мәҗлесе турында ни дә булса әйткәне күзебезгә чалынганы юк. Авыз ачтырганда бер кешеме, биш кешеме, тугыз кешеме, туксан кешеме булырга тиеш – андый чикләү юк. Берәү ураза тотучыны авыз ачтырса, сугышка китүче кешене коралландырса, шуңа йөз шаһиднең дәрәҗәсе бирелә, дигән хәдис бар. Монда саны әйтелмәгән бит. Никадәр күп кешене авыз ачтырса, әҗер-савабы шулкадәр күп булачак. Кунак тугыз да, алтмыш та булырга мөмкин. Чик куймаска кирәк. Чөнки бөтен кешенең дә хәле бер төрле түгел. Кемнең өе бик кечкенә, кемнең милке зур түгел, кемнең ураза тотучылар арасыннан туганнары, танышлары бик аз. Моңа бик күп мисал китерергә мөмкин. Шуңа күрә, авыз ачу, ифтар мәҗлесендә тугыз кешең булмады, дип, дәгъва белдерү бик тә урынсыз.




**– Рамазан аенда ураза тоткан кешегә аракы сатарга ярыймы? Аның тоткан уразасы кабул буламы? Хәзер бу эш белән күпләр шөгыльләнә.**

– Мондый хәдис бар: «Аракыны ясаучы да, ясатучы да, сатучы да, саттыручы да, эчүче дә һәм эчерүче дә гөнаһлы була». Хәдистән аңлашылганча, үзе эчмәсә дә, аның аракы сату белән шөгыльләнүе гөнаһлы гамәлләрдән санала.

**– Ураза тотканда, әгәр намаз укымасаң, иртән сәхәр алдыннан һәм кич ифтар алдыннан тәһарәт алу фарызмы?**

– Ураза тотар өчен яки авыз ачтыру өчен тәһарәт алу шарт түгел. Тәһарәт ул – намаз укыр өчен махсус пакьләнү, һәм ул – бик зур корал. Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) бер хәдистә әйткән: «Тәһарәт белән йоклаучы кеше, көндез руза тотып, кичен уяу торган кебек әҗерле була», – дигән. Янә дә: «Берәүнең җаны алынганда ул тәһарәтле булса, шаһид дәрәҗәсендә үлә», – дигән сөенечле сүзләр бар. Ләкин, тәһарәт алып та, намаз укымаса, ул кеше коралны хәтерләтә. Хәзерләп тә ул коралын файдаланмыйча, бушка исраф итүче кебек үкенечкә кала, дигән риваятьләр язылган.

**– Сәхәр ашамаган кешенең уразасы дөресме?**

– Ураза тотарга ниятләгән кеше таң атканчыга кадәр ашамый һәм сәхәрсез ураза тота икән, аның уразасы дөрес була, ләкин савабы азрак. Чөнки Мөхәммәд пәйгамбәр (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) сөннәтенә кергән бер гамәлне эшләмичә калдыра.

**– Көн буе йокласаң, ураза дөресме?**

– Ураза дөрес, чөнки йокы уразаны бозмый. Ләкин шуны истә тотарга кирәк: ураза безгә күп йоклау һәм ашау өчен түгел, ә рух күтәренкелеге, яңа белем алу, иманны ныгыту һәм тәкъвалыкка ирешү өчен кирәк.

**– Рамазан аенда хайван-кош чалырга ярыймы?**

– Рамазан аенда да, башка айларда да хайван-кош чалу тыелмый, фәкать Аллаһ исемен зикер итү, ягъни «Бисмилләһи, Аллаһу әкбәр», дип әйтү кирәк.

**– Уразада телевизор карау ярыймы?**

– Телевизор карау гомумән ураза һәм тәһарәтне бозмый. Әмма әхлаксызлык, сугыш, үтереш һәм җенси теләкне уята торган программалардан ерак булу кирәк, алар мөселман өчен тыелган. Төрле юк-бар программалар карау уразалы вакытта ураза тотуның савабын киметә, уразага зәгыйфьлек китерә. Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) әйткән: «Ураза үзенне ризыктан гына тыю түгел, ураза ул үзеңне начар гадәтләрдән, начар күренешләрдән дә саклау», – дигән.

Әхлакый тәрбия бирә торган программаларны, дини тапшыруларны, ил хәбәрләрен карарга ярый.

**– Без әле соңгы елларда гына ураза тота башладык. Ә калган уразаларны ничек каза кылырга икәнен белмибез.**

– Әгәр дә сау-сәламәт булсагыз, гомер буена калган уразаларыгызны үтәп чыгыгыз. Аллаһы Тәгалә куәт-ярдәмен бирсен. Әйтик, сез 10 ел буена ураза тотмагансыз икән, 10 ай ураза тотарга тиеш буласыз. Тик Рамазан ае җиткәч, шушы елның уразасына керерсез. Калган еллар уразасын үтәргә керешкәндә: «Йә Раббым! Ният кылдым гомерем буена калган фарыз уразаларны үтәргә...» – дип ниятләргә онытмагыз. Ураза тотуның тәртип- кагыйдәләрен дә исегездә тоту хәерле.

Әгәр авыру икәнсез, ул вакытта 10 еллык уразаны 300 көн тотарга тиеш буласы. Әгәр ураза тотарга гаҗиз икәнсез, һәрбер көн өчен бер фәкыйрьне туендырырлык ризык яки ризык алырлык акча белән тәэмин итәргә тиеш буласыз.

**Габделхак хәзрәт Саматовның «Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-савап, киңәшләр» китабыннан**

**Газетаны гамәлгә куючы**
«Путь» хәйрия фонды.
Газета Татарстан мөфтияте рөхсәте белән бастырыла

**Редакция шурасы**
Рәисе – Дагстан республикасы мөфтие, Әхмәд хаҗи АБДУЛЛАЕВ

Татарстан республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

Мәскәү Ислам институты ректоры Дамир ХӘЙРЕТДИНОВ

**Баш мөхәррир**
Н. М. МӘХМҮТОВА

**Мөхәррир**
Ләйлә ХӘСӘЕНОВА

**Баш мөхәррир урынбасары**
Фәрит Батыршин

**Гамәлгә куючы мөхәррир**
Мөхәммәт РӘХИМОВ

**Әдәби мөхәррир**
Рәйсә СӘГАДИЕВА

**Менеджмент**
Абдулсабир АХМЕДОВ

**Веб-версия**
Мөхәммәтрасул ЗАҺИРОВ

**Компьютер төркеме**
Ренат ИСЛАМОВ
Гайсә ОМАРОВ

Газета зарегистрирована Федеральной службой по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций. Свидетельство о регистрации ПИ № ФС 77-42079 от 24 сентября 2010 г.

**Индекс 35888.**
**Подписка в любом почтовом отделении России.**
При перепечатке ссылка обязательна.
Набрано и свёрстано на компьютерной базе газеты «Ас-Салам».
Отпечатано в филиале ГУП МО «КТ» «Мытищинская типография» по адресу: 141009, Московская область, г. Мытищи, ул. Колонцова, 17/2.
Заказ №**720**. Тираж **2300** экз.
Подписано в печать (факт) 15.04.2017 в 10:00
(график) 15.04.2017 в 10:00
**Адрес редакции и издателя:**
367015, РД, г. Махачкала, ул. Ярагского, 128.
**E-mail:** assalamweb@gmail.com. **www.as-salam.ru**
**Телефоны**
Редакция: +7-904-662-18-75 , +7-928-530-59-70
Подписка и доставка по РТ: +7-987-172-2000
Отдел распространения по РФ: +7-926-222-78-75